# ХАЛЫК ЖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“25” ноябрь 2023 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 25 ноябрендә «Сез 2024 елда Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, 1 төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар, мобилизацияләнгән гражданнар, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Көек авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агач һәм куак кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- янгын сүндерү җиһазларын саклау өчен җайлаштырылган бина төзү өчен төзелеш материаллары сатып алу (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
- Югары Көек авылының урам юлларын грейдлау, кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә мәсьәләләрен кабул итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ»
мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 151 (бер йөз илле бер) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 77 ( җитмеш җиде) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 77 (җитмеш җиде) кеше тавыш бирде;
«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.
2. “Сез 2024 елда Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнар, 1 төркем инвалидлар, көндезге формада укучы студентлар, мобилизацияләнгән гражданнар, РФ Оборона министрлыгы белән контракт төзегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Югары Көек авылы территориясен чистарту, үлән чабу, агач һәм куак кисү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү;
- янгын сүндерү җиһазларын саклау өчен җайлаштырылган бина төзү өчен

төзелеш материаллары сатып алу (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

- Югары Көек авылының урам юлларын грейдлау, кардан чистарту (эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

Экономия ясалган очракта, аерым мәсьәләләр буенча Түбән Көек авыл җирлеге башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен акча җибәрергә рөхсәт итәргә мәсьәләләрен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Түбән Көек авыл җирлеге Югары Көек авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Түбән Көек авыл җирлеге башлыгы Галиәхмәтов Д.М.